ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Яр Буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә Кәрим Тинчурин һәм Урман урамы №5 һәм №7 йортлардан 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 7

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Яр Буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә Кәрим Тинчурин һәм Урман урамы №5 һәм №7 йортларда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 10 000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Яр Буе Морквашы торак пункты Кәрим Тинчурин һәм Урман урамы №5 һәм №7 чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ____________ И.Х.Гаязов